**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

06.12.2017 1465-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чаралары уздыруга биремнәр һәм аларның эчтәлекләрен рәсмиләштерү һәм юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чаралары нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибен раслау турында

"Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында" 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 8.3 статьясының 4 өлеше, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында" 2014 елның 21 августындагы 603 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чаралары уздыруга биремнәр һәм аларның эчтәлекләрен рәсмиләштерү һәм юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чаралары нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Татарстан Республикасының әйләнә-тирәлекне саклау өлкәсендәге дәүләт инспекторларына юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чараларын әлеге Боерык белән билгеләнгән Тәртиптә бирелә торган биремнәргә нигезләнеп уздырырга.

3. Хокукый тәэминат бүлегенә (М.Р. Галиәкбәров) шушы боерыкның дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

4. Бу боерык үтәлешен тикшереп тору буенча министр урынбасары Ф.Ф. Шакировны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр Ф.С Габделганиев

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигый
ресурслар министрлыгының
2017 елның 06 декабрендәге
1465-п номерлы боерыгы
белән расланды

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чаралары уздыруга биремнәр һәм аларның эчтәлекләрен рәсмиләштерү һәм юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чаралары этиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибе

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чаралары уздыруга биремнәр һәм аларның эчтәлекләрен рәсмиләштерү һәм юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чаралары нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибе (алга таба – Тәртип) юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чараларын уздыруга биремнәр (алга таба – бирем) әзерләгәндә һәм биргәндә Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгындагы (алга таба – Министрлык) вазыйфаи затларның эш башкару чорларын һәм эзлеклелеген билгели.

2. "Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында" 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба – 294-ФЗ номерлы Федераль закон) билгеләнгән Юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чараларын (алга таба – контрольлек чаралары) оештыру һәм уздыру тәртибе.

3. Контрольлек чарасы уздыруга бирем территориаль идарә башлыгы тарафыннан рәсмиләштерелә һәм министр урынбасары – Татарстан Республикасында әйләнә-тирәлекне саклау өлкәсендә Баш дәүләт инспекторы тарафыннан раслана.

4. Контрольлек чараларын уздыру биремендә түбәндәгеләр булырга тиеш:

контрольлек чарасын уздыруга биремнең датасы һәм номеры;

үзенә карата контрольлек чарасы уздырыла торган оешманың тулы һәм кыскартылган аталышы, ИНН, ОГРН, оешманың адресы (урнашкан урыны);

контрольлек чарасын уздыру чорлары;

контрольлек чараларын уздыруга әлеге бирем нигезендә контрольлек чараларын уздыру вәкаләте бирелгән вазыйфаи затның яисә вазыйфаи затларның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

контрольлек чараларының исемлеге:

- "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, оешмаларның зарури таләпләрне үтәвен күзәтү;
- оешма эшчәнлеге турында мәгълүматны анализлау юлы белән зарури таләпләр үтәлешен күзәтү, аны бирү бурычы оешмаларга йөкләнгән.

5. Министрлыкның территориаль идарәләре юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чараларын уздыруга биремнәрне әлеге Тәртип кушымтасында билгеләнгән формалы теркәүгә алу журналын алып бара.

6. Контроль чаралары нәтиҗәләре бәяләмә рәвешендә рәсмиләштерелә, анда түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

контрольлек чарасы уздыруга биремнең датасы һәм номеры;

үзенә карата контрольлек чарасы уздырыла торган оешманың тулы һәм кыскартылган аталышы, ИНН, ОГРН, оешманың адресы (урнашкан урыны);

контрольлек чарасын уздыру чорлары;

контрольлек чараларын уздыруга әлеге бирем нигезендә контрольлек чараларын уздыру вәкаләте бирелгән вазыйфаи затның яисә вазыйфаи затларның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

оешманың зарури таләпләрне үтәве турында һәм (яисә) оешма эшчәнлегендә ачыкланган зарури таләпләр бозылу турында мәгълүмат;

бәяләмәне төзү датасы;

контрольлек чарасын уздырган вазыйфаи затның яисә затларның имзасы.

7. Бәйләнешкә кермичә гамәлгә ашырыла торган контрольлек чараларын уздырганда зарури таләпләр бозылу очраклары ачыкланган очракта, бәйләнешкә кермичә контрольлек чарасын уздырган затлар үз компетенциясе чикләрендә мондый бозуларны чикләү буенча чаралар күрә, шулай ук, 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясының 2 өлешендәге 2 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш тикшерү билгеләү турында карар кабул итү зарурлыгы булганда, ачыкланган бозулар турында мәгълүматлар белән, территориаль идарә башлыгына язмача рәвештә дәлилләнгән йогынты актын җибәрә.

8. Юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чараларын уздыру барышында зарури таләпләрне бозарга әзерләнү яисә бозу билгеләре турында белешмәләр алынган очракта, территориаль идарә башлыгы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Зарури таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтү төзү һәм җибәрү, юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан мондый кисәтүгә ризасызлыклар тапшыру һәм аларны карау, мондый кисәтүне үтәү турында хәбәр итү кагыйдәләрен раслау турында" 2017 елның 10 февралендәге 166 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә, юридик затка яисә шәхси эшкуарга зарури таләпләрне

бозуның ярамаганлыгы турында кисәтү җибәрә һәм юридик затка, шәхси эшкуарга зарури таләпләр үтәлешен тәэмин итү буенча чаралар күрергә һәм бу хакта мондый кисәтүдә билгеләнгән чорда (кисәтү җибәрелгән көннән соң кимендә 60 көн) Министрлыкка хәбәр итәргә тәкъдим итә.

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чаралары уздыруга биремнәр һәм аларның эчтәлекләрен рәсмиләштерү һәм юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чаралары нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибенә кушымта

РӘВЕШЕ

Юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чаралары уздыруга биремнәрне теркәүгә алу журналы

| № п/п | Бәйләнешкә кермичә контрольлек чарасы уздыруга биремнең датасы, бирелү датасы | Бәйләнешкә кермичә контрольлек чарасы уздыруга җаваплы булган вазыйфаи затның Ф.И.А. | Үзенә карата бәйләнешкә кермичә контрольлек чарасы уздырыла торган юридик затнын/шәхси эшкуарның аталышы | Бәйләнешкә кермичә контрольлек чарасы уздыру чоры | Бәйләнешкә кермичә контрольлек чарасының төре | Бәйләнешкә кермичә контрольлек чарасы нәтиҗәләре турында белешмәләр |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |